**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ОЛЫ ШИЛНӘ АВЫЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**КАРАР**

«16» ноябрь, 2023 ел №8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Олы Шилнә авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, өлешчә мобилизацияләү буенча РФ Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын тыш, 2000 (ике мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Олы Шилнә авылында юлларны ремонтлау;
2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;
3) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау
4) тротуарны төзекләндерү
5) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)
6) Коймаларны төзекләндерү һәм урнаштыру
7) чишмәне төзекләндерү

2. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Олы Шилнә авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г. Даутов